**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Советы карары**

2020 елның 15 июне №128

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 14 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 3 пунктының, 86 статьясындагы 5 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Балтач ав., Мәктәп ур., 1;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Балтач ав., Мәктәп ур., 2 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы Д.И. Мөхәмәдуллин